КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 октябрь г.Казань № 859

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 24 гыйнвар, 45 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр белән (эш урыннарын оештыру, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидлар сайлау мәсьәләләре буенча) һәм буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, инвалидлар арасыннан гражданнар өчен һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар үзара хезмәттәшлеге тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр белән (эш урыннарын оештыру, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидлар сайлау мәсьәләләре буенча) һәм буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, инвалидлар арасыннан гражданнар өчен һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар үзара хезмәттәшлеге тәртибен һәм

шартларын раслау турында» 2022 ел, 24 гыйнвар, 45 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының эш бирүчеләр белән (эш урыннарын оештыру, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын да кертеп, буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен инвалидлар сайлау мәсьәләләре буенча) һәм буш эш урыннарын, вакантлы вазыйфаларны биләү максатларында, шул исәптән инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында, инвалидлар арасыннан гражданнар өчен һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар үзара хезмәттәшлеге тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең
эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлеге

Эш урыннарын (инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын, буш эш урыннарын биләү өчен инвалидларны сайлап алуны кертеп) оештыру мәсьәләләре буенча эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан «Инвалидларны эшкә алу һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге ТРЗ-60 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләренең федераль дәүләт стандартлары нигезендә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда һәм гражданнарга яраклы эш эзләп табуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Хезмәт базарында конкурентлык сәләтен арттыру, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм  күрсәтү һәм инвалидларны эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен киңәйтү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чаралары кысаларында инвалидларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне (алга таба – белем бирү) оештыруны гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин